КЫЙММӘТЛЕ КАЛДЫКЛАР

Татарстан Дәүләт Советы калдыклар турындагы законны камилләштерү тәкъдимен Думага юллаячак

> 2

ТӨЗИБЕЗ ДӘ ТӨЗИБЕЗ

Эшче куллар һәм төзелеш чималлары җитәме соң?

> 3

ТАРИХИ БОЛГАР

Шәхесләрне бик тиз онытабыз түгелме?

> 3



ИМАН ЙОРТЫ

Казандагы «Рауза» мәчете башкаларыннан нәрсәсе белән аерылып тора?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 171 (28944) | Шимбә | 19 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

ҮЗГӘРӘБЕЗ ТҮГЕЛМЕ?

Россия мәктәпләрендә укучылар бердәм формадан йөри башларга мөмкин. Дәүләт Думасына әнә шундый закон проекты кертелгән. Әлеге тәкъдимне Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцов та хуплаган. Тик замана балалары барысын да бер калыпка кертүләрен теләрме соң?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бөтенроссия җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ) уздырган сораштырудан күренгәнчә, әти-әниләрнең 80 проценты мәктәп формасын кире кайтару яклы. Хәзерге вакытта киенү кагыйдәләрен төбәкләр үзләре билгеләде. Бездә бу яктан проблема юк анысы.

– Татарстан мәктәпләрендә бердәм форма күптән кертелде. Һәр мәктәпнең үзенеке бар. Россиядә барлык төбәкләрдә дә андый нәрсә юк. Хәзер Россия Мәгърифәт министрлыгы бердәм кагыйдәләр кертә. Мәктәпкә ертык джинсыдан яки чуар күлмәктән йөрү бетә дигән сүз. Дөрес, бердәм дигәч, ул без укыгандагы кебек, кызлар мәктәпкә көрән күлмәктән, ак яки кара алъяпкычтан киләчәк дигән сүз түгел. Малайлар да зәңгәр костюмнан гына йөрмәячәк. Һәр мәктәпнеке үзенчә булачак. Бездә форманың төсен, фасонын мәктәпләр үзләре сайлый. Салкын вакытта балаларга җете төстә булмаган җылы кофталар кияргә рөхсәт ителә, – диде Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат үзәге җитәкчесе Алсу Мөхәммәтова.

Бу уңайдан Татарстан Иҗтимагый палатасының Мәгариф һәм фән буенча комиссиясе әгъзасы Ирек Закировның да фикерен сораштык. Аның әйтүенчә, җәмгыятьнең үз кануннары бар, шуларны үтәргә кирәк. Башбаштакланырга кирәкми.

– Бала мәктәпкә теләсә нинди киемнән барып булмавын, кечкенәдән киенү кагыйдәләрен белеп үсәргә тиеш. Ул форманы һәрвакыт чиста тотарга кирәк. Бердәм киемнең тәрбияви ягы да бар. Әлбәттә, ул балаларга ошарга тиеш, – ди Ирек Закиров.

Ул, үзенең мәктәп елларын да искә төшереп: «Сугышның яңа гына беткән чагы… Без укыганда, форманы каеш буып кияләр иде. Ирләр арасында хәрбиләрнекенә охшаган кием кию бик популяр иде. Фуражкасы да бар. Аннан аны бетерделәр. Аерым мәктәп формасы кирәк, әлбәттә», – диде.

«Барысы да бер инкубатордан чыккан сыман булмасмы соң?» – дигәнгә:

«Дөньяда гел бала-чага фикерен тыңлап кына яшәп булмый бит. Кайбер мәсьәләләрдә болай да артык ирек бирәбез. Һәр баланың кыяфәтеннән аерым шәхес икәнлеге күренеп тора. Әгәр күлмәге ап-ак, үтүкләнгән булса, әти-әнисе бик пөхтә дип уйлыйсың. Үтүкләнмәсә, ботинкасын чиста тотмаса, кире фикер туа. Инкубатор баласы булып йөрергә теләмиләр, дип, ялкау кеше генә әйтә», – дип җавап бирде Ирек Мөнир улы.

Казандагы 149 нчы лицейның башлангыч сыйныф укытучысы Гөлүсә Садыйкова бердәм форманың социаль аерманы тигезләвен әйтә.

– Берәүләр көн саен яңа өс-баш кияргә, икенчеләрнең моның өчен акчасы булмаска мөмкин. Бердәм булганда, баймы ул, ярлымы – аерма күренми. Барысы да – укучылар, – ди Гөлүсә Садыйкова. – Бездә берәүнең дә, туйдык, киясе килми, дигәне юк. Минем сыйныфта сарафан, итәк, киң чалбар киючеләр дә бар. Икенче параллель сыйныфта барысы да сарафаннан, шикәрдәй ак блузкадан йөриләр. Тукымадан ясаган значок, галстук тагалар. Кызларның чәчләре үрелгән. Үземнең укучылар белән чагыштырганда, алар ялт иткән. Бердәм кием – үзе бер матурлык.

Яңа Чишмә районының Зирекле авылы мәктәбендә 53 бала укый. Монда укучылар ретро формадан йөри. Дөрес, кайберләренең заманчарак та киенәсе килә икән. Директор Айрат Хәммәтвәлиев белдергәнчә, андыйлар сирәк. Бердәм форма дәүләт югарылыгында бердәмлекне дә күрсәтә, бу – тәртип билгесе.

Яшьләр арасында бердәм форманы үз итүчеләр дә, бик үк өнәп бетермәүчеләр дә бар.

– Мәктәп формасы – иң җайсыз нәрсә ул. Килешәм, тәртип ягыннан бертөрлелек кирәктер. Әмма укыганда аны салып атасы килгән чаклар да аз булмады. Беренчедән, кара төстә, ямьсез. Икенчедән, кызуда тәнне кычыттыра. Эчне пошыргач, ничек тыныч күңел белән укып булсын, ди? Үзеңне уңайлы хис иткән киемнән йөргәндә, уку да җиңелрәк дип уйлыйм. Бердәм форма булдырганчы, хет балаларны зәвык белән киенергә өйрәтсеннәр иде. Минемчә, эшлекле стиль кертү күпкә отышлырак, – ди 23 яшьлек менеджер Алинә Сабирова.

Бу уңайдан Илсөя Бәдретдинова төркемендә чыгыш ясаучы Айысхааннаның да фикерен сорадык.

– Бердәм форманы бетерделәрмени аны? – дип гаҗәпләнде ул башта. Аннан сүзен бик оптимистик рухта дәвам иттереп: «Мин мәктәпне алты ел элек тәмамладым. Якутия авылында бу. Без ак күлмәк, итәктән йөрдек. Бик горурланып кия идем. Мәктәпләрдә киенү тәртибе бер-берсеннән күпмедер дәрәҗәдә аерыла. Бу очракта синең кайсы уку йорты укучысы икәнлегең күренеп тора. Син күзгә кебек. Бердәм форма кирәк, әлбәттә», – диде ул.

Яңа уку елы башланганнан бирле, мәктәпләрдә дәүләт әләмнәрен күтәрәләр. «Мөһим сөйләшү» дәресләре кертелде. Тәрбияне дә искә төшерделәр. Хәзер бердәм форма кертмәкчеләр. Үзгәрәбез түгелме? Әллә үткәннәргә кайтып барышмы? Хәерлегә булсын!

Үзләре түләгәннәр

Ел башыннан бирле Татарстанның суд приставлары коллекторлык фирмаларыннан 186 тапкыр штраф түләткән. Алар вакытында капланмаган бурычны кире кайтаруда кешеләрнең хокукларын санга сукмаган. Суд приставлары хезмәте идарәсе хәбәренә караганда, коллекторлардан барлыгы 9,5 миллион сумнан артыграк штраф түләтелгән. Иң еш очрый торган гаепләре – бурычлыларның үзләрен, якыннары һәм туганнарын телефон аша даими борчып тору, чит номерлардан хәбәрләр җибәрү.

Машинаңны белеп куй

Быел Татарстанда инвалидлар өчен билгеләнгән урыннарга машина куйган өчен 2730 тапкыр штраф түләтелгән. Республика автомобиль инспекциясеннән хәбәр ителгәнчә, 1602 автомобиль штрафстоянкага озатылган.

Инвалидларның машина урыннары, уңайлырак булсын өчен, бина ишегенә якынрак урнаштырыла. Дәүләт автомобиль инспекторлары мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең урыннарын сау-сәламәт йөртүчеләр алу-алмавын тикшерү максатында даими рейдлар үткәреп тора. Анда еш кына тиешсез машиналарны куеп китүләре ачыклана. Исегезгә төшерәбез: инвалидлар урыннарына машина куйган өчен штраф күләме 5 мең сум тәшкил итә.

Районнарга барып юаталар

Татарстан психологлары мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләренә ярдәм итү өчен районнарга чыга башлаган. Яшьләр эшләре министры урынбасары Алла Кондратьева әйтүенчә, Саба, Лаеш һәм Алексеевск районнарында хәрби хезмәткәрләрнең якыннары белән шундый эш башлап җибәрелгән. Әлмәт, Чаллыда психологик-педагогик ярдәм үзәкләрендә гаиләләргә дәресләр уздырыла.

Моннан тыш мобилизацияләнүчеләрнең якыннары Татарстанда балалар өчен бердәм ышаныч телефоны (8-800-2000-122) һәм яшьләр өчен бердәм ышаныч телефоны (8-800-5552-220) аша психологик ярдәм сорап мөрәҗәгать итә ала. Өлешчә мобилизация башланганнан бирле 105 кешегә шундый ярдәм күрсәтелгән инде. Моннан тыш, «Ярдәм янәшә» республика «Кайнар линиясе»нә (8-800-350-02-16), тәүлек әйләнәсе эшләүче «Сердәш»кә (8 (843) 279-55-80) шалтыратырга мөмкин.

Дуңгыз гриппы, метапневмовирус...

Быел Татарстанга 2009 елгы H1N1 штаммы килә. Моннан 13 ел элегрәк бөтен дөнья күләмендә котырган дуңгыз гриппы бу. Роспотребнадзор идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина әйтүенчә, 2020 елда гripптан авыручылар булмаган, ә 2021 елда коронавирус сәбәпле кертелгән эпидемиягә каршы чаралар нәтиҗәсендә инфекцияне йоктыручылар аз санда теркәлгән. Аның әйтүенчә, халык чирләмәгәч, чиргә карата табигый иммунитет та кимегән. Иң элек йөкле хатын-кызларның, 65 яшьтән өлкәнрәкләр һәм балаларның инфекция йоктыру куркынычы зур. Нәкъ менә шулар беренче чиратта прививка ясатырга тиеш.

Бүгенгә Россиядә грипп йоктыруның 70тән артыграк очрагы теркәлгән. Шуның 70 проценты – дуңгыз гриппы. Узган атнада Татарстанда да бер кеше шуны йоктырган. Шул ук вакытта «метапневмовирус» дигән инфекция көчәеп киткән. Узган елда ике кеше генә чирләсә, быел инде 57 авыру очрагы теркәлгән. Ул башлыча сулыш юлларының югары өлешен зарарлый. Әмма инфекция еш кына түбәнгә төшеп, бронхит һәм сулыш юллары ялкынсынуга да китерә. Инфекция, башка вируслар белән кушылып, чирне көчәйтергә мөмкин, ди Любовь Авдонина.

Яңалык

Барысына да түлиләр

Татарстанда махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына 20 мең сум акча түләргә дигән карар чыкты. Шулай итеп, акчага дәгъва итүчеләрнең исемлеге киңәйтелде.

Әлеге документ нигезендә 20 мең сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган акча өлешчә мобилизация кысасында хәрби хезмәткә чакырылган барлык гражданнарның балаларына биреләчәк. Рәсми документта элегрәк булган республикада даими теркәлүгә кагылышлы пункт исә гамәлдән чыгарылган.

ШУЛАЙ ИТЕП, АКЧАЛАТА ЯРДӘМ КЕМНӘРНЕҢ БАЛАЛАРЫНА ТИЕШ?

✓Росгвардиядә хезмәт иткән һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына. Аларның исемлеген республиканың хәрби комиссариаты төзи. Соңрак әлеге исемлек социаль яклау органнарына җибәрелә.

✓Эчке эшләр министрлыгы һәм Иминлек федераль хезмәте идарәсе хезмәткәрләре балаларына. Аларның исемлеген хезмәт итү урыннарыннан җибәрәчәкләр.

✓«Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби бурычны үтәүчеләрнең балаларына. Алар турында мәгълүматны шулай ук республиканың хәрби комиссариаты бирәчәк.

✓Башка төбәкләр территориясендә өлешчә мобилизация кысасында хәрби хезмәткә чакырылучылар һәм үз теләкләре белән махсус хәрби операция зонасында катнашучыларның балаларына. Республикада теркәлгән һәм башка субъектлардан чакырылган гражданнарның балалары башка төбәктә чакырылыш фактын раслаучы документлар нигезендә 20000 сум күләмендә акча алачак.

Эльмира ЗАРИПОВА, Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры:
– Акчалата ярдәмне алу өчен, мобилизацияләнгәннәрнең хатыннарына Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге филиалларына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Алар Татарстанның һәр районында бар. Үзәкләрдә гариза тапшырырга, аңа баланың туу турында таныклыгын да беркетергә кирәк. «Әти» графасында мобилизацияләнгән кешенең исеме күрсәтелергә тиеш. Акча күчерү өчен исәп-хисап счетын да күрсәтү кирәк.

✓Республикада теркәлмәгәннәрнең балалары да акчага өмет итә ала. Аларның даими рәвештә Татарстан территориясендә яшәве шарт.

Әлеге акчалата түләү Татарстан бюджетының резерв фондыннан башкарылачак. Республиканың Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы чыгымнар турында хисапны Финанс министрлыгына 2023 елның 20 гыйнварына кадәр тапшырырга тиеш, диелә карарда.

Сүзгә-сүз

Илья НАЧВИН, Татарстан дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрының беренче урынбасары:



«Татар-информ» / С.Исхаков

Узган елда Татарстанның Дәүләт хезмәтләре порталы аша 29 миллиард сумлык түләү башкарылган. Элегрәк бу сан 23–24 миллиард сум арасында тирбәлә иде. 2020 елда пандемиягә бәйле рәвештә портал аша түләүчеләр саны артты. Дәүләт хезмәтләре порталының нәтиҗәлелеген дә исәпләп чыгардык. Ул елына уртача 18 миллиард сум тәшкил итә.

(«Татар-информ» агентлыгында әңгәмәсеннән)

СЕЗ БӘХЕТЛЕМЕ?

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россия халкыннан шул хакта сорашкан.



ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Кояш Җир тирәли әйләнсә...

«Соңгы 20 елда илдә китап уку, китап аша дөньяны танырга омтылу кискен кимеде. Сәбәбе – глобальләшкән массакүләм мәгълүмат чаралары һәм күңел ачу индустриясенең ашкын үсеше». Казанда КФУ мәйданында узган Халыкара лингвистик саммитта чыгыш ясаганда Россия мәгариф академиясе президенты, элегрәк Россия мәгърифәт министры Ольга Васильева шулай дип белдерде.

Белгечләр россияле кавемнең яртысына якынының китапны гомумән кулына да тотып карамавын, укымавын әйтә. Китап бит әле ул әдәби әсәрләр генә түгел, ул – фәнни-популяр басмалар, документаль язмалар, публицистика, башкасы да. Кешене, Тукайчарак әйткәндә, яктылыкка, нурга илтүче чара ул. Тик, күрүебезчә, халыкның яктылыкка чыгасы бик килми. Чөнки аң-белем – шундый нәрсә: ул сиңа көнендә-сәгатендә өеп дивидендлар китерми. Моны гавам аңлый һәм күрә. Төп сыйфат – урнаша белү. Хәзерге көн бәндәне «юк-бар» белән баш катырмаска, яшәп калырга, булдыра алганча рәхәт чигәргә, кулланучы, файдаланучы булырга чакыра. Хәтта власть структуралары да шуңа өнди. «БДИ атасы» булган икенче бер элекке мәгърифәт министры Андрей Фурсенконың биек мөнбәрдән әйткән сүзләрен әле дә хәтерлибез: «Совет системасы иҗади затлар тәрбияләргә тырышты. Безгә андыйлар кирәкми. Без квалификацияле кулланучы тәрбияләргә тиеш». Янәсе, көчәнмә, уйларга, уйлап табарга, булмаганны булдырырга тырышма, җайлы яшә. Менә сиңа чит илдә эшләнгән гаджет, менә сиңа иномарка – рәхәтен күр. Әнә бар-рестораннар, чит-ятлар җитештергән товарлар белән тулы кибетләр – тормыштан барын да алып кал.

Тормыштан барысын да алу дигәндә, исемлеккә, аңлашыла ки, интеллект, киң эрудиция, төпле белем дигән нәрсәләр керми. Белгәннәрең дипломыңдагы тар белгечлек кысасына сыйса, шул җиткән. Ул гынамы, хәтсез очракларда диплом булганда да белем такы-токы гына. Гомумән, югары белем, инде ике-өч дистә еллар булыр, девальвация кичерә: дипломлылар күп, белемлеләр аз. Дипломда күрсәтелгән белгечлек буенча эшләүчеләр дә артмый, азая кебек. Бу аңлашыла да, башка юнәлешкә кереп киткәннең үз юнәлешендәге наданлыгы атлаган саен кычкырып тормый чөнки. Бүген илдәге фәннең шактый мөшкел хәлдә булуыннан зарланалар. Кулланучы әвәләргә юнәлеш алынгач, наданлык гаеп саналмагач, фән белән шөгыльләнүче тинтәкләрне каян тапмак кирәк?! Фән белән мәгарифкә бүленгән акча гыйльми хезмәткәрләр һәм укытучылар кызыгырлык окладларда чагылмагач, ул өлкәләр ничек алга китсен?!

Гыйлем, мәгърифәт, дигәндә, башка тарафларда, илләрдә хәл ничек тора соң? Күпләргә мәгълүм IQ (интеллект дәрәҗәсе) россияле кавемдә башкалардан артыкмы, кимме? Инглиз профессоры Ричард Линн төзегән исемлеккә караганда, әлеге күрсәткеч буенча Россия – дөньяда 33 нче урында. Җир шарында 200гә якын ил барын исәпкә алсаң, соңгы елларда китап укымаган, аң-белем дип чәчрәп чыкмаган ил өчен бу бер дә начар түгел кебек. Әмма IQ дигәндә, шул ук японнарның бездән күпкә башлырак икәнен әйтми ярамастыр – алар 3 нче баскычта. Беренче унлыкта Көньяк Корея, Австрия, Германия, Италия, Тайвань, Швеция, башкалар. Әлеге рейтингны ышанычлы халыкара оешмалар һәр елны төзеп торган башка исемлек – дөнья илләрендәге тормыш дәрәҗәсе рейтингы белән чагыштырыйк. Анысына карасаң, Россия белән Япония арасында шактый тирән упкын ята: японнар 16 нчы урында булса, без – 67 нче баскычта. Әле тагын уңышлылык һәм чәчәк ату индексы (LPI – Legatium Prosperiti Index) дигәне, шулай ук ел саен төзелеп торган рейтинг та бар. Анысында без – 70 нче урында. Ә японнар – безнең буй җитмәгән 18 нче баскычта. Әлеге чагыштырулардан чыккан төп нәтиҗә шундый: гыйлем, интеллект, укымышлылык алга сөрелгән тарафларда тормыш начар була алмый һәм андыйлар һәрдаим үсештә кала.

Гомуми гыйлемлелек, технологияләр, югары тормыш сыйфаты, чәчәк ату – бер-беренә бәйле юнәлешләр һәм рейтингларга караганда, саналганнар әлегә безгә янамый. Халыкара исемлекләрдә югары үрмәли алмауны кемнәрдер Россиянең территориаль зурлыгы, зур илдә тәртип урнаштыруның авырлыгы, салкын климатка бәйле зур энергетик чыгымнар белән акларга тырыша. Тик ул чагында Канада дигән ил LPI (уңышлылык һәм чәчәк ату индексы) буенча ник 5 нче урында? Бәлки Россия тоташ булдыксызлар, эш сөймәсләр ватаныдыр? Юк, аңа да охшамаган. Әмма булдыксызлык дигәндә, аның иҗтимагые да бар бит әле. Хикмәт бәлки шунысындадыр. «Дәүләт ул – без!» – дип әйтә белмичә, ирек-хөрлеккә һуш китмичә, башны иеп, Некрасовтагыча: «Вот придет барин – барин нас рассудит», – дип яшәүдән ни көтеп була? Юаш, аң-белемгә тартылмаган кулланучы илне күтәрә аламы? Сорау риторик.

Гыйлемле, актив, акыллы халыкның хакимияте дә гадәттә акыллы, ипле була, халык белән санлаша. Бездәге власть халыктан читтәрәк яши һәм үз дигәнен эшли, дисәм, көфер сүз әйтмәм кебек. Үтә байларның бар тырышканы – бүгенгене консервацияләү, үзләре төзегән оҗмахны саклап калу. Нәкъ шул сәбәпле салым түләүче кесәсеннән алынган триллионнарның аз өлеше генә мәгариф белән фәнгә, мәдәнияткә китә. Европа һәм АКШ университетларының Россиядәге әйдәп баручы вузларга караганда 5–10 тапкыр күбрәк финанслануы мәгълүм. Азчылык халыкларга исә үз университетларын булдыру гомумән дә мөмкин эш түгел.

Язма ахырында мәгълүм физик Сергей Капица моннан ун-унбиш еллар элек әйткән сүзләрне китерәсе килә. «Мин хөкүмәт әгъзаларына әйттем: илдә гыйлемгә мөнәсәбәтне үзгәртмәсәгез, диваналар ватаны тудырачаксыз. Андый ил белән идарә итү җиңел, тик аның киләчәге юк, дидем». Чыннан да, бүген без гаджетлар аша смайлик, лайклар куеп сөйләшүче тулы бер буын үстердек. Аларның бер өлеше өчен Кояш булып Кояш та хәзер Җир тирәли әйләнеп йөри...

ТР Дәүләт Советында

АКЧА, АЛИМЕНТ, БАКЧА ҺӘМ БАШКАЛАР

tatarstan.ru

Парламентның 37 нче утырышы көн тәртибе беренче карашка бераз «сыеграк» тоелды. Чөнки һәр утырыштагы кебек, депутатлар, нигездә, федераль законнар тирәсендә әйләнделәр. Әмма туктап-туктап сөйләрлек мәсьәләләр дә бар иде. Сүзне «тормышыбыз тоткасы» – бюджеттан башлыйк әле.

2023 елга һәм 2024–2025 еллар план чорына Республика бюджеты закон проекты ике утырыш арасында озаклап, тәфсилләп тикшерелде. Шушы вакыт эчендә аңа 701 төзәтмә тәкъдим ителгән иде. Шуның 660ы – Министрлар Кабинетыннан, 24е – депутатлардан, 17се – Бюджет, салым һәм финанслар комитетыннан. Парламент «иләге» аша үткәрә торгач, төзәтмәләр саны 677гә калды. Әлеге санның шактый зур булуына шаккатасы юк, чөнки төзәтмәләрнең күбесе федераль казнадан килгән акча хисабына үз казнабызны тәгаенләүгә кагыла иде.

Бюджет, салым һәм финанслар комитеты рәисе Леонид Якунин әйтүенчә, 2023 елда федераль акча күләме 9,9 миллиард сумга артачак һәм 61,8 млрд сумга җитәчәк. Акча булгач, керер урыны табыла инде ул. Бу хакта соңрак берничә сүз әйтербез. Ә акча санарга яратучыларга берничә сан китерә торыйк. Закон проектына төзәтмәләрне исәпкә алып, 2023 елга бюджет кереме – 343 млрд 933 млн 710 мең, ә чыгым өлеше 371 млрд 0,81 млн 210 мең сум булыр, диделәр. Ә кытлык 27 млрд 147 млн сум тәшкил итәчәк икән. Алга таба керемнәр ел саен ике миллиард сум тирәсенә артып барачак үзе, ә кытлык кимемәячәк.

Кайсы өлкәгә күпме акча китәсен әйтеп тормыйбыз инде. Ә менә көтелмәгән чыгымнар булырга мөмкин, чөнки дөньясы тотрыксыз. Һәрхәлдә, ачка үлмәбез, картлар әйтмешли, «дөньялар гына тыныч булсын». Бу уңайдан, Дәүсоветның Россия Думасы Рәисе Вячеслав Володинга мөрәҗәгате уйландырды. Социаль сәясәт комитеты рәисе Светлана Захарова әйтүенчә, безнең депутатларга мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган ирләрнең хатыннары мөрәҗәгать итә башлаган. Сүз балигъ яшькә җитмәгән балалары булган аналар, мохтаҗ гаиләләр турында бара. Мәгълүм булганча, федераль закон гадәттән тыш хәлләр аркасында хәрби хезмәткә алынган ирләрне алимент түләүдән вакытлыча азат итә. Ә матди ярдәмгә мохтаҗ гаиләләр нишләргә тиеш? Светлана Захарова әйтүенчә, алиментлар хисабына яшәүче гаиләләр аз түгел икән. Инде нишләргә? Комитет рәисе, мәсьәләне хәл итүнең юлы бар, ди. Россия Президенты Владимир Путин имзасы белән быел сентябрьдә чыккан Указ өлешчә мобилизациягә эләккәннәргә хәрби хезмәт башкаручы статусы бирә, ә аларга дәүләт шактый гына акча түли. Безнекеләр шул акчадан алимент тотып калуны күздә тота да инде. Россия Думасы Дәүсовет мөрәҗәгатенә күз йоммас дип уйлыйк та, «алиментщик»ларга кая барса да котылу юк инде дип, моңсу гына елмаеп куйыйк. Шул ук вакытта мохтаҗ гаиләләр дә, балалар да кызганыч бит.

Хәрби операцияләр, ничек кенә борсаң да, акча сорый инде ул. Медицина иминиятләштерүе фондына бирелергә тиешле субвенцияләрнең алдагы елларга арта торуы да шуңа бәйледер, дип уйлыйбыз. Фонд бюджеты турындагы закон проекты белән депутат Камил Нугаев таныштырган иде. Аның әйтүенчә, фондка керергә тиешле акчалар киләсе елга – 3,3 млрд сумга, 2024 елга – 4,3, 2025 елга 7,8 млрд сумга артачак. Тулаем алганда, фонд бюджеты кереме һәм чыгымы 2024 елга – 75,1 млрд, ә 2025 елга 78,8 млрд сум булачак. Бюджет кытлыгы юк. Камил Нугаев әйтмешли, күпме керә, шул хәтле чыга инде.

Ярый, болар турында бик эчкә кермик, керсәң чыгасы була. Бакчачылык ширкәтләренә кагылышлы закон проекты күпләрнең күңеленә якын, дип уйлыйбыз. Премьер-министр урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров әйтүенчә, бүген Татарстанның 23 районында 1883 ширкәт бар икән. Әмма аларның эшчәнлеген җайга салу өчен, шактый мәсьәләләрне хәл итәсе бар. Депутатлар хөкеменә тәкъдим ителгән закон проекты кайбер ширкәтләрнең яки торак пунктлар составына керүе, яки мөстәкыйль торак пунктка әйләнүе өчен аерым шартлар тудыруга, критерийлар билгеләүгә кагыла. Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе Азат Хамаев, бу мәсьәлә инде күптән өлгерде, дип саный. Закон проекты бердәм хупланды.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Чүпкә дә тәртип кирәк!

Татарстанның Дәүләт Советы депутатлары Россия Федераль Җыены Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володинга һәм РФ Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустинга сыек көнкүреш калдыклары белән эш итүне хокукый яктан көйләү турында мөрәҗәгать әзерләгән. Аны Татарстан Дәүләт Советының 37 нче утырышында депутатлар хуплады.

Утырыштан соң, Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисе Александр Тыгин, Дәүләт Думасы депутатлары Айрат Фәррахов һәм Марат Нуриев журналистларның кайбер сорауларына җавап бирделәр.

Александр Тыгин үзәкләштерелгән су чыгару системасына тоташтырылмаган йортларда сыек көнкүреш калдыклары белән эш итү тәртибе закон нигезендә регламентланмаган дип саный.

– Азкатлы йорт янәшәсеннән сыек калдыклар махсус транспорт белән җыеп алына һәм чыгарыла. Андый коммуналь хезмәтләргә тарифлар да җайга салынмаган, – ди Александр Тыгин. – Сыек көнкүреш калдыклары белән эш тәртибенең тулы циклын булдыру кирәк. Бу – аларны тарифлаштыру, транспорт белән алып китү, чистарту, утильләштерү. Шулай ук, су агызуның үзәкләштерелмәгән системасы хезмәтләренә дәүләт тарифларын кертү кирәк. Без бу юнәлештә эшләргә риза. Моның өчен Россия Хөкүмәтеннән җавап кирәк.

Элек сыек калдыкларны чыгару Россия Хөкүмәте Карары белән расланган кагыйдәләр нигезендә эшләнгән, ә 2021 елның 1 гыйнварыннан алар үз көчен югалткан. Мондый хезмәтләрнең бәясе ике яклы килешүдә катнашкан яклар тарафыннан билгеләнә. Сыек көнкүреш калдыклары белән эш тиешенчә җайга салынмау әйләнә-тирә мохитнең торышына тискәре йогынты ясый һәм кешеләрнең сәламәтлегенә дә куркыныч тудыра. Сер түгел, калдыклар еш кына елга-күлләргә түгелә. Шуңа күрә дә Александр Тыгин, сыек калдыкларны түгүче машиналарга ГЛОНАСС системасы куйдырту кирәк, ди. Шулай ук аларның халыкка хезмәт күрсәткән өчен бәяләрне үзләре куюы да депутатларга ошап бетми. Озын сүзнең кыскасы, тәртип кирәк!

– Бездә чүп реформасы 2019 елда башланса да, әлегә кадәр көтелгән нәтиҗәләр күренми. Тарифлар артты, халыкта сораулар күбәйде, әмма аңа карап чүплекләр саны кимемәде. Бу өлкәдәге хаталар буенча эшләргә кирәк, – ди Айрат Фәррахов. – Татарстандагы тәкъдимнәр Михаил Мишустинга җибәрелү белән бергә, төрле министрлык һәм ведомстволарда да каралачак. Без экспертларның соңгы сүзен 1–1,5 ай эчендә ишетергә тиеш. Бу закон проектын эшләп бетереп, аны Дәүләт Думасында күтәрәчәкбез.

Марат Нуриев исә, Дәүләт Советында күтәрелгән калдыклар проблемасы Татарстан өчен генә түгел, бөтен ил өчен дә әһәмиятле, дип белдерде.

– Моның өчен безгә халыкның ярдәме кирәк. Калдыкларга карата мөнәсәбәтне үзгәртү, аларны аеру һәм эшкәртү, чүпкә хуҗалар табу һәм аларга җаваплылык билгеләү кирәк, – ди Марат Нуриев.

Яңалыклар кертелгәч, калдыклар чыгаручы өчен бәяләр артып китмәсме? Александр Тыгин, бу хакта сүз дә була алмый, ди. Аның фикеренчә, калдыклар өчен түләү йортта ничә кеше яшәүдән һәм чүп җыючы төбәк операторы белән төзелгән килешү санынннан тора. Мисалга ул Яшел Үзән районының бер авылын китерде. Анда элек чүпне яр буйларына, чокырларга гына ташлап барганнар. Төбәк операторы килгәч, алар Казанда яшәүчеләр белән бер төрле бәя түләп чүп чыгара башлыйлар.

– Бар да килешүдән тора. Кешеләр күп мәгълүматны белми, – ди Александр Тыгин. – Чүп реформасы турында күбрәк сөйләргә, күбрәк язарга кирәк. Бу эштә безгә халык белән беррәттән журналистлар да ярдәм итәр дип өметләнәбез.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасының шәһәрләрне үстерү институты» фонды директоры урынбасары **Камалова** Венера Айдар кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

КАЙГЫРТКАНГА АРТАЛАР

Табигать сагында

Акрынлап кышка аяк атлыйбыз. Бу чорны кыргый хайваннар ничек кичерә? Аларга азык җитәрлекме? «Урманнарда азык әзер, барысына да җитә», – ди Татарстан Биоресурслар буенча комитетының хайваннар дөньясына күзәтү бүлеге мөдире Илфат Вәлиев.

– Елына ике тапкыр яз һәм көз айларында безнең хезмәткәрләр, республиканың аучылык биләмәләрендә җимлекләр, утлыклар урнаштырып, кыргый хайваннарны ашата. Тоз, салам, ашлык һәм башка төрле азыклар әзерләнә. Алар җәнлекләрнең кайбер төр авыруларга каршы торучанлыгын арттырачак һәм күченеп йөрүдән коткарачак, – ди белгеч. – Азык булгач, хайваннар салкыннарны да тыныч үткәрәчәк.

Кыргый хайваннарны мәктәп укучылары да кайгырта. Тәтеш районының Килдеш мәктәбендә укучылар урманда яшәүчеләргә үзләреннән өлеш керткән. Кем нәрсә алып килә ала, шуны китергән. Куяннарны уйлап, кишер алып килүчеләр шактый.

– Мин табигать кочагында булырга бик яратам. Элек урманга әти-әнием белән йөри идем. Хайваннарны сыйларга килүем беренче генә тапкыр. Мин, аларны ашатучы кеше юктыр, алар үз көннәрен үзләре күрәдер, дип уйлый идем. Урманнан шатланып кайттым, аларны ашатучы, кайгыртучы кешеләр җитәрлек икән, – ди Арина Горбунова.

tatarstan.ru

Кыргый хайваннар кайчан тамак туйдыра? Баксаң, аларның күбесе тамагын төнлә туйдыра икән. Минзәлә районының дәүләт ау күзәтчелеге идарәсе җитәкчесе Ринат Шәйхетдинов әнә шулай ди.

– Кыргый хайваннарның йөрү юлларына азык тутырылган җимлекләр куябыз. Анда тоз, яфрак, печән салына. Тояклылар өчен тоз бик кирәк. Кайбер төр хайваннар өчен бодай да салабыз. Алар төнлә ашап йөри. Бик сирәк вакытта гына көндез утлык янына килгәннәрен күрәсең, – ди Ринат Шәйхетдинов. – Тиздән, кар төшкәч, аларның санын ала башлаячакбыз. Әлегә су кошларын исәпләдек. Шунысын әйтә алам: хайваннар саны елдан-ел арта.

Татарстанда кыргый хайваннар кышка курыкмыйча керә ала. Татарстанның Биоресурслар буенча комитеты белгечләре сүзләренә караганда, урманнарда алар өчен әзерләнгән азык күләме җитәрлек. Республикада җәнлекләр өчен 346 җимлек ясалган. Аларга 24317 килограммнан күбрәк ашлык салынган, 532 себерке әзерләнгән. Кыргый хайваннарны кайгырту аларның үрчүенә китерә. Әйтик, 10 ел эчендә пошиларның саны, ике тапкыр артып, 13,5 мең булган. Кыр кәҗәләре исә 6 тапкыр арткан. Аларның баш саны хәзер 12,5 меңгә җиткән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Борчылу

ЭЛЕККЕ ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ БОЛГАР

Менә шундый баш астында язучы Нурихан Фәттах 1965 елда зур гына мәкалә бастырган («Татарстан яшьләре», 15 июль). Әлеге мәкаләдә автор Болгар турында кыскача белешмә биргән: кемнәр алар болгарлар, каян, кайчан килеп чыкканнар, ни белән шөгыльләнгәннәр һәм башкалар. Яшь чагында, төгәлрәк әйтсәк, 1957–1958 елларда Нурихан Мәскәү профессоры Алексей Петрович Смирнов җитәкчелегендә археологик казу эшләрендә катнашкан. Смирнов инде 1937 елдан бирле Болгардагы археологик эзләнүләргә җитәкчелек иткән, 1944 елда шушы тема буенча докторлык диссертациясе дә яклаган булган.

Болгарга сәяхәт. Тәүфикъ Әйди завод яшьләрен оештырып алып барган иде. Зәлап кеше басуда куныл, арып-талып, белем алып кайттык. 19 июнь, 1966 ел.

1960 нчы еллар. Без Киров районындагы Большая Крыловка дип аталган урамда үз йортыбыз белән яшәп ятабыз. Шул елларда безгә яшь кенә бер егет килеп йөри башлады. Тәүфикъ исемле (сүз язучы Тәүфикъ Әйди турында. – **Ред.**). Ул вакытларда берниндди телефон-фәлән юк, алдан хәбәр итеп булмый, Тәүфикъ та алдан әйтмичә теләсә кайсы көнне, теләсә кайсы вакытта килеп керә иде. Яшь булса да, укымышлы һәм кызыксынучан бу егет белән Нурихан дуслашып китте – сөйләшеп сүзләре бетми, кайчакта бәхәсләшеп тә алалар. Аларның сөйләшүенә кысылмасам да (сөйләшеп утырырга вакыт та юк: бала кечкенә, өйдә эш күп, институтта укыган вакыт – имтиханнарга әзерләнергә кирәк), колакка керә бит сүзләре. Ишетсәм дә, дөресен генә әйткәндә, миңа аларның сөйләшүләренең бер кысылы да юк иде – һаман бер үк сүз: татар да Болгар, Болгар да Биләр...

1966 ел. Шушы елның җәендә Тәүфикъ Оргсинтез заводы яшьләрен оештырып (үзе шул заводта аппаратчы булып эшләгән икән), безне Болгарга экскурсиягә алып китте. Кырыклап кеше булгандыр. Анда завод яшьләреннән тыш, башка олырак кешеләр дә барды. Академия театры артисты Габдулла Шамуков, хатыны һәм әтисе белән КОМЗ заводында эшләүче инженер Мәлик Мөхәммәтҗанов, булачак галим, ИЯЛИ хезмәткәре Нурмөхәммәт Хисамов һ.б. Барыбыз да куна бардык, төнне йокламыйча учак янында уздырдык, бик күңелле булды. ИЯЛИнең фәнни хезмәткәре Фоат Вәлиев тә, Болгар турында сөйләр өчен, барыргa ризалык биргән булган икән. Ләкин хакимият әһелләре аны дирекция ярдәмендә бу эштән читләштергәннәр. Бу рольне, ягъни Болгар турында белешмә бирүне Нуриханга башкарырга туры килде. Нурихан мине баштан ук: «Анда КГБ вәкилләре дә булырга мөмкин, теләсә кем белән сөйләшмә, минем янда гына йөр», – дип кисәтеп куйды. Нәрсә сөйләшим ди инде мин чит кеше белән? Ау кисәтүгә, билгеле, артык игътибар итмәдем. Аннан соң, КГБ кешесенең үзенә дә кызык түгелмени хан заманындагы кешеләрнең ничектерә яшәгәнен белү. «Мәскәүнең үзеннән килеп, Болгар тарихын өйрәнгәннәр, шул турыда китаплар язганнар, нишләп аларны уку яисә белмәгән кешегә сөйләү гаеп булсын инде?» – дип уйладым мин ул вакытта. Ялгышканмын, сөйләргә ярамаган икән шул.

«Болгар тарихы мәсьәләсендә мәгълүм булган күп кенә ачышлар турыдан-туры профессор Смирнов исемене бәйле», – дип язган Нурихан Фәттах әлеге мәкаләсендә. Язучы алга таба Болгарның юкка чыгу куркынычы барлыгын кисәткән, алай гына да түгел, бу тарихи объектны саклап калу өчен үзенең тәкъдимнәрен дә язган.

Дөньялар үзгәрде, бүген «яңа» Болгарны танырлык түгел. Бу урынга меңнәрчә турист йөри. Ислам университеты ачылды. Болгар «Юнеско» оешмасының исемлегенә кертелде. Бу гамәлләрнең барысы да беренче Президентыбыз Минтимер Шарипович Шәймиев тырышлыгы белән эшләнде. Аның тарихта, һичшиксез, матур эзе калачак, халкыбызның олы хөрмәтенә лаеклы булган бу шәхес белән бер чорда яшәвемә горурланам.

Быел ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу уңаеннан бик күп чаралар үткәрелде, йөзләгән фәнни һәм фәннипопуляр мәкаләләр басылды, шул исәптән, әлбәттә, дин әһелләре дә үзләренең фикерләрен, куанычларын белдерделәр. Ләкин миңа укырга туры килгән бер язмада да профессор Алексей Петрович Смирнов исеме күренмәде, ислам дине кабул ителүне әдәби әсәрдә һәм күп санлы фәнни мәкаләләрендә күтәреп чыккан Татарстанның халык язучысы Нурихан Фәттахны искә төшерүче дә табылмады. Киләсе елга мәрхүмнең вафатына егерме ел була, бик тиз онытабыз түгел микән?

Руфина ФӘТТАХОВА,
Нурихан Фәттахның хатыны, медицина фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган табибы

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз җиденче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 353-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

3. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 344-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

4. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 345-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

5. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында бизнес алып бару һәм инвестицион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 350-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

6. «Татарстан Республикасында граждашарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 352-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

7. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 349-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасында халыкка адресълы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 355-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 357-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. 2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы проекты турында.

11. «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына карауга бирү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

12. Сыек көнкүреш калдыклары белән эш итүне хокукый җайга салуны камилләштерү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында.

13. «Үтәү эшен алып бару турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясына үзгәрешләр кертү зарурлыгы хакында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате турында.

14. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында» 2019 елның 11 июлендәге 2983-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

15. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетының 2019 елның сентябреннән 2022 елның ноябренә кадәрге эш чорына хисабы.

16. Татарстан Республикасында җәмәгать юстициясе эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе мәгълүматы.

17. «Ядкарь» генеалогия проекты турында мәгълүмат.

18. «Корал турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1196104-7 номерлы федераль закон проекты турында.

19. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 197803-8 номерлы федераль закон проекты турында (авыр үтелә торган җирләк, су, тау объектлары, спелеологик һәм башка объектлар буенча уза торган, тормыш өчен аеруча куркыныч тудыручы, туристларның (экскурсантларның) саламәтлегенә һәм аларның мөлкәтенә зыян салуга бәйле булган хәрәкәт итү маршрутлары буенча мәгълүмат бирү тәртибен бозган өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).

20. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законның 126 һәм 134 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 212656-8 номерлы федераль закон проекты турында (бурычлыдның чираттан тыш каплана торган чыгымнары өлешендә).

21. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 208706-8 номерлы федераль закон проекты турында (санкцияләргә каршы ярдәм чараларын дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне арендага алучыларга карата куллану мәсьәләсе буенча).

22. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законның 15 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 221974-8 номерлы федераль закон проекты турында (кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерә торган оешмалар исемлеген авыл хуҗалыгы кооперациясе өлкәсендә компетенцияләр һәм фермерларга ярдәм үзәге белән тулыландыру өлешендә).

23. «Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 19 һәм 29^1 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 217653-8 номерлы федераль закон проекты хакында (пассажирлар йөртүгә рөхсәте булган йөртүче тарафыннан пассажирлар йөртү вакытыннан алда туктатылганда, пассажирларны вакытлыча йөртүне оештыру турында һәм, хәрәкәттә чикләүләр кертелгәндә, маршрутларны үзгәрту яисә юкка чыгару хакында).

24. «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 41 статьясына үзгәреш кертү турында» 217224-8 номерлы федераль закон проекты хакында (түләүле автомобиль юллары буенча мәктәп автобусларының түләүсез йөрүе хакында).

25. «Россия Федерациясе Торак кодексының 23 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 209283-8 номерлы федераль закон проекты хакында (торак (торак булмаган) урынны торак булмаган (торак) урынга күчерү процедурасын камилләштерү өлешендә).

26. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2022 елның 18 ноябре
№ 1680-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп өч елга түбәндәгене сайларга:

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Яңа Савин суд районы буенча:

6 нчы суд участогына – Фәйзуллина Диана Рәшит кызын.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп вәкаләтләр чоры чикләнмәгән вакытка түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Лаеш суд районы буенча:

2 нче суд участогына – Клюев Игорь Анатольевичны;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Мәскәү суд районы буенча:

6 нчы суд участогына – Егоров Роман Владимировичны;

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча:

21 нче суд участогына – Хәмидуллина Диләрә Гамир кызын;

Татарстан Республикасы Ютазы суд районы буенча:

1 нче суд участогына – Кәримова Гөләндәм Зиннур кызын.

3. Әлеге карарның 2 пункты нигезендә сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы Егоров Роман Владимировичның һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы Кәримова Гөләндәм Зиннур кызының вәкаләтләр чоры алдагы вәкаләтләр чоры тәмамланган көннән башлана.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2022 елның 18 ноябре
№ 1681-VI ДС

Сөремле көпшә «бүләге»

Электрон тәмәке үпкәләргә коронавирус белән бер дәрәҗәдә зыян сала. Компьютер томографиясе нәтиҗәләре шуны күрсәткән.

Казан шәһәре Сәламәтлек саклау идарәсенең баш пульмонологы Рөстәм Хәмитов сүзләренә караганда, тәмәке тарту аркасында килеп чыккан үлем-китемнәрнең саны СПИДтан үлү очраклары белән бертигез диярлек. «Әммә соңгысына кеше сагаеп караса, тәмәке тартуны исә җитди кабул итми, бармак аша гына карый», – дип белдерде белгеч Бөтендөнья тәмәкедән баш тарту көненә багышланган матбугат очрашуында.

Росстат мәгълүматларына караганда, бүген халыкның 20 процент чамасы тәмәке көйрәтә. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш психиатр-наркологы Резеда Хәева сүзләренчә, соңгы елларда Россиядә тәмәке тартучылар саны кими бара:

– Моңа нигездә тәмәке бәясе арту, җәмәгать урыннарында тәмәке тартуны тыю сәбәпче. Пандемия чорының да йогынтысы булды. Ул чорда табиблар, коронавирус йоктыру ихтималын киметү өчен, шушы начар гадәттән баш тартырга киңәшләрен дә искәртеп торды.

Белгечләр соңгы арада яшьләр арасында аеруча популяр булган электрон тәмәке, вейпларның аеруча куркыныч булуын искәртә. «Организмга берниндди зыян салмый, киресенчә, хәтта тәмәкене ташларга ярдәм итә» ише фикерләрне дә уйдырма дип атый алар. Күпләр әнә шул сүзләргә каба да инде. Рәсми саннардан исә чәчләр үрә тора. 2016 елга 1,5 миллион мәктәп баласы тәмәке тарткан булса, 2019 елда аларның саны 5 миллионга җиткән.

– Тәмәке җитештерүчеләр бик хәйләкәр. Алар тәмәкедән аның шушы яңа чыккан җиңелчәрәк төрләре ярдәмендә котылырга өнди. Араларында хәтта минем янга килеп, электрон тәмәке зарарсыз дип рәсми рәвештә белдерүемне сораучылар да булды. Алар табыш артыннан куа. Шул ук 2016 елда электрон тәмәке сатудан гына да 16 миллиард сум табыш алганнар. Нигездә, безнең яшьләр кесәсеннән чыккан акча бу, – ди Рөстәм Хәмитов.

Тәмәке тарту үпкә яман шешеннән тыш тагын 16 төрдәге яман шеш (ирен, тел, йөткылык, трахея, ашказаны һ.б.) китереп чыгара. Тәмәке тарткан кешедә ревматоидлы артрит та пәйда булырга мөмкин. Әйтик, егерме яшеннән башлап бөрөзлексез тәмәке тарткан кешегә 30–35 яшьләрендә инде шушы диагноз куелырга мөмкин. Ул исә – үз чиратында, инвалидлыкка ук китерә торган чир.

Республика клиник онкология диспансерының табиб-онкологы Марат Бакиров сүзләренә караганда, узган ел Татарстанда 1,5 мең үпкә яман шеше очрагы теркәлгән.

– Шуларның 80 процентын тәмәке тартучылар тәшкил итә. Кызганыч, яман шешнең бу төре елдан-ел яшәрә бара. Үпкә яман шеше белән авыручыларның күпчелеге (70 процент) – ир-атлар. Кызганыч, бүген тәмәке көйрәтүче хатын-кызлар саны да арта, – ди белгеч.

Берочтан кальянның да сәламәтлек өчен зарарлы булуын искәртте ул. Аның аша хеликобактер пилори, туберкулез таякчыгы, герпес, ОРВИ йоктырырга мөмкин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Төзүчеләр – алда

Татарстанда төзелешнең туктап торганы юк, эшчеләргә кытлык сизелми, материаллар җитәрлек. Журналистлар белән очрашуда Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Илшат Гыймаев әнә шулай диде.

Торак төзү буенча Татарстан – Россиядә бишенче, Идел буе федераль округында – беренче урында. Узган ел республикада 3011,5 мең кв. метр торак төзелеп, файдалануга тапшырылган. Илшат Гыймаев әйтүенчә, быел шуннан ким булмаячак, хәтта берәз арттырып җибәрергә дә җыеналар. Әлегә 2990,1 мең кв. метр тапшырылган. 2030 елга исә әлеге күрсәткечне 3500 мең кв. метрга җиткерү нияте бар.

– Татарстанда торак йортлар төзү дәвам итә. Әйтик, Казандагы «Салават күпере» торак комплексында күп кенә йортлар тапшырылуга әзер. Алданган өлешчеләр дә тынычлап йоклый башлады. 18 меңгә якын гаилә куллына ачкыч алды инде. Түбән Кама һәм Казанда тагын икешәр объектны төзеп бетерәсе бар. Шуның белән аларның проблемасы хәл ителә, – ди Илшат Гыймаев.

Министр урынбасары әйтүенчә, социаль әһәмияткә ия булган төзелеш объектларының күбесе сентябрь башында ук тапшырылган инде. Мәктәпләр, балалар бакчалары, спорт объектлары ачылды. Авылларда мәдәният йортлары, ФАПлар сафка басты. Быел «Сәламәтлек саклау» икълем проекты буенча 33 объектта төзү һәм төзекләндерү эшләре планлаштырылган. Шулардан 29ында эш тәмамланган инде. Республика программасы буенча быел 23 ФАП төзелгән. «Демография» икълем проекты кысасында Алабуга һәм Яшел Үзәндә мәдәният үзәкләре эшли башлады. Илшат Гыймаев планлаштырылган төзелеш эшләре ел ахырына тәмамланыр дип өметләнә. Питрәч районының Көек авылында ФАП, Арча районында һәм Мамадыш шәһәрендә бакчалар төзелеп бетүне көтәләр.

Очрашуда шулай ук соңгы арада фатирларга ихтыяҗ кимегәне дә әйтелде.

– Халык җәйге айлардагы кебек фатир алырга атлыгып тормый. Күпләр икенчел базардагы фатирларны карый. Яңа төзелгән йортлардагы куышлыны тәртипкә китерү өчен дә тырышырга кирәк. Ә инде икенчел базардагысына кер дә яшә. Алар бер-берсенә комачау итми. Киресенчә, тулыландырып кына тора. Ә без исә яңа фатирларны сатуга күбрәк игътибар бирәбез, – диде министр урынбасары.

Төзибез дә төзибез. Эшче куллар һәм төзелеш чималлары җитәме соң? Баксаң, бар да тәртиптә икән. Элек чит илләрнең кайберләреннән кергән кирәк-яракларны алыштыру җаен тапканнар, үзебездә булмаганны безнең белән дустанә мөнәсәбәттә булган илләрдән алалар икән. Эшчеләргә дә кытлык юк. Киресенчә, төзүчеләргә эш җитми икән әле.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«Шаян ТВ»га – дүрт!

«Шаян ТВ» беренче балалар телеканалы үзенең 4 еллык туган көнен билгеләп үтә. Телеканал үз эшчәнлегенә быел нинди нәтиҗәләр ясый? Туган көне уңаеннан, яраткан тамашачыларына нинди бүләк әзерләгән? Матбугат очрашуында әнә шулар турында сөйләделәр.

– Моннан 4 ел элек Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов хәер-фатихасы белән «Шаян ТВ» – татар телендә эшли торган беренче һәм бердәнбер телеканал – эфирга чыга башлады. Президент безнең алга балалар, милләтебез өчен файдалы проектлар булдыру максатын куйды. Бүген шул максатларны истә тотып эшлибез. Ел саен берничә яңа проект әзерлибез. Халкыбызның бай мирасын саклауда «Шаян ТВ»ның өлеше зур булырга тиеш, – диде телеканалның баш мөхәррире Рамилә Сәхабетдинова.

Проектлар дигәннән, быел «Татар сүзе» нәфис сүз бәйгесе беренче тапкыр телевизион форматта уза. Бәйгегә 3100 гариза килгән. Рамилә Сәхабетдинова «Татар сүзе»ндә балаларның да күп катнашуын билгеләп үтте.

– Бу безне бик шатландыра. Яшь буын татар сүзенең ямен, тәмен белеп үсәргә тиеш. «Татар сүзе» – бик җаваплы һәм кирәкле проект. 10 меңгә якын татар кешесен шушы бәйгегә җәлеп итә алдык икән, без моңа бик сөенәбез. Җиңүчеләр гала-концерты киләсе елның 26 апрелендә булачак, – диде баш мөхәррир.

Сүз – көмеш, җыр – алтын дигәндәй, «Шаян ТВ» телеканалы инде өченче ел рәттән, балалар өчен яңа җырлар барлау максатыннан, «Балачак җыры» бәйгесен оештыра. Быел шул җырларны тамашачыга җиткерү өчен, мәктәпләрдә һәм мәдәни үзәкләрдә концертлар үткәрә башлаганнар. Рамилә Сәхабетдинова сүзләренә караганда, 25 ноябрь көнне «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә «Сәйлән» фестивале җиңүчеләре катнашында зур концерт булачак.

Автор-башкаручы, «Сәйлән» телевизион җыр фестиваленең жюри әгъзасы Илгиз Шәйхразыев фестивальдә катнашучыларны югары бәяләде.

– Беренчедән, балаларның остазлары әйбәт, икенчедән, алар белән әти-әниләре шөгыльләнергә иренми. Конкурсның таләпләре бик югары. Таләпләр югары булгач, сыйфат та үсә, – диде ул.

Мөхәррирләр бүлеге җитәкчесе Резедә Хәсәнова телеканалның тамашачыларына туган көне уңаеннан нинди бүләк әзерләвен әйтте.

– Быел бу – безнең өр-яңа «Яраткан шигырь» проекты. Әлеге проект балаларга шигырьләр аша татар халкының тарихы, гореф-гадәтләре, бай мирасы һәм мәдәнияте белән танышырга ярдәм итә, – ди ул. – Балалар үзләре дә бик теләп катнаша. Чөнки монда без кечкенә генә фильм да төшерәбез. Шушы проектны караганнар классик һәм хәзерге заман шагыйрьләребезнең иҗаты белән кызыксына башлар, дип өметләнәбез.

«Шаян»нардан – бүләк

«Шаян ТВ» балалар телеканалында оештырылган «Балачак җыры» телевизион музыкаль проекты җиңүчеләре Казанның 18 нче татар гимназиясе укучыларына концерт бүләк итте.

shayantv.ru

Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән оештырылган «Балачак җыры» бәйгесенең максаты татар телендә балалар өчен җырлар иҗат итүче шагыйрь һәм композиторларны барлау, шул җырларны таныту, балалар репертуарын татар җырлары белән баетудан гыйбарәт. Ул инде өченче ел рәттән уздырыла.

18 нче гимназиядә узган концертта Татарстан Дәүләт Советы депутаты Камил Нугаев та бар иде. Ул мәктәп укучыларын ТР Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов исеменнән сәламләде:

– Бик шатланып килдем сезгә. Уку елы башында мәктәпнең яңа бинасы ачылышына Марат Әхмәтов та килгән иде. Аның тырышлыгы белән тормышка ашкан хыял бу. Бик яхшы, татар мохитле гимназия, дип кайтты. Аңа бик зур рәхмәт. Телевизордан гына түгел, балалар үз күзләре белән күрсен дип, мәктәпләргә концертлар белән киләбез. Телне җыр, мәдәният аша үстерүдә «Шаян ТВ» үткәрә торган «Балачак җыры» бәйгесенең роле зур.

Дәүләт Советы депутаты фикеренчә, элеккеге балачак җырлары хәзерге балаларга кызык булмаска мөмкин. Үзенчәлекле, заманча җырлар кирәк.

– Хәзерге балалар бик алдынгы, аларның белмәгәннәре юк. Бәйге композиторларны, шагыйрьләрне таба һәм алар иҗат иткән яңа җырларны балаларга җиткерә. Алга таба да шулай тырышып эшләгез, – диде ул.

18 нче гимназия директоры Гөлшат Фәсхетдинова концертны оештыручыларга рәхмәт сүзләрен җиткерде:

– Безгә шундый матур туган тел бәйрәме бүләк иткәнегез өчен, зур проектның бер өлеше булырга мөмкинлек тудырганыгыз өчен рәхмәт сезгә. Бүген безнең алда яшь, талантлы, матур артистлар чыгыш ясады. Татар телебез белән горурланып, ана телебездә сөйләшкән балаларыбыз булганда, телебезнең киләчәге бик матур булыр дип өметләнәбез.

Сүз уңаеннан, бу концертны Казанның Яңа Савин районындагы 177 нче лицей һәм Совет районының 180 нче гимназиясе укучылары өчен дә куячаклар.

Ләйсән САФИНА

ИЛНУР ХӘЗРӘТ ВАФИН:

«КЕШЕГӘ МӘЧЕТТӘ РӘХӘТ БУЛЫРГА ТИЕШ»

Иман нуры ишектән үк иңә башлый. Һәрхәлдә, Казанда яңа ачылган «Рауза» мәчетендә шулай. Монда каршы алудан башлап, озатып калуга кадәр үзебезчә – татарча, түшәм белән диварлары да рәхәт мохит өсти. Мәчет тә татар символикасына бик бай. «Рауза» мәчете имам-хатыйбы Илнур хәзрәт ВАФИН белән Аллаһ йортының үзенчәлекләре, мәчеттә дин тотучылар өчен каралган мөмкинлекләр турында сөйләштек.

rauza-m.ru

:: Илнур хәзрәт, «Рауза» мәчетенә килгәнче, «Яндекс.Карта» хезмәте аша гыйбадәт урыны турында халык фикерен укыдым. Барысы да мәчетнең матурлыгын, мондагы мөнәсәбәтне ассызыклый. Сездән дә сорыйк инде: «Рауза» мәчете Казандагы башка мәчетләрдән нәрсәсе белән аерылып тора?

– Мәчетне бу елның сентябрь аенда ачтык. Аллаһ йорты бик тиз арада – 1 ел да 5 айда төзелде. Мәчетне салыр алдыннан Радик Рәүф улы Гайзатуллин (республиканың финанс министры. – **Авт.**), безне җыеп: «Егетләр, республикадагы мәчетләрне карап чыгыгыз әле», – диде. Төп максат – мәчетләрдә булган минусларны яңа мәчеттә булдырмау иде. Республикада яңа салынган гыйбадәтханәләрне карап чыктык, үзебезгә нәтиҗә ясадык. Без алдан ук уйлаган нечкәлекләр иде ул. Иң элек – мәчеткә керү. Керә торган урын кечкенә, чишенү бүлмәсе тар, чыгарга бер генә ишек. Аннан тәһарәтханә мәсьәләсе. Шулай ук күп урында ул кечкенә, начар ис бар, дымлылык зур. Барысын да әйтеп бетереп тә булмый. Бер караганда бу – көнкүреш сораулары. Безнең максат кеше өчен мәчетебезне уңайлы итү иде. Мәчетнең намаз залы никадәр затлы, матур булмасын, гардеробта, тәһарәт алу урынында тәртип, чисталык юк икән, бу матурлыкка игътибар да итүче булмый.

Икенче максатыбыз – мәчетнең эчке мохитен матур итү. Монда басып тору да рәхәтлек, тынычлык бирергә тиеш. Бу җәһәттән дә тырыштык. Мәчетебез «Рауза» исемен йөртә. Бу – ана исеме. Димәк, Аллаһ йортында да әни тематикасына урын бирелергә тиеш иде. Әйтик, мәчеткә керә торган җирдә үк әниләр исеменнән балаларга фатиха рәвешендә нәсыйхәт эленеп тора. Анда барысы да – тел дә, милләт тә исәпкә алынган. Аны язып биргән апаларга Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булсын. Мәчет эчендә исә – бу тематикага багышланган Коръән сүрәләре, аятьләр. Монысы инде – безгә, балаларга, Аллаһ сүзе. Гарәп телендә шәмаил рәвешендә ясарбыз дип уйлаган идек. Ә Радик Рәүф улы безгә аны, һичшиксез, татарча да ясатырга киңәш итте. Дөрестән дә, барысы да гарәп телен белми бит. Киләчәктә мәчет эчендә диварларга хәдисләрдән өзекләр беркетергә җыенабыз.

Дизайнга килгәндә, аны танылган Дмитрий Мусин һәм аның хатыны Лилия эшләде. Аңа баштан ук: «Мәчеттә барысы да татарча, милли булырга тиеш», – дидек. Башкаларны да карадык, барысы да матур, сүз дә юк. Әмма без нәкъ менә миллилеккә йөз тоттык. Мәчет – гасырларга төзелә торган бина.

МӘЧЕТ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ

«Рауза» мәчете Сеченов урамы, 21 йорт адресы буенча урнашкан. Иман йорты 1,4 мең кв. м мәйданны били.

Өстәмә мәгълүмат алу өчен телефон: **+7 987 226-50-50.**

«Рауза» да, Аллаһ боерса, озак еллар эшләр. Шуңа күрә киләчәкне уйлап, нигезне салып калдырасыбыз килде. Килгән һәр кеше биредәге орнамент, төсләрне дә күңелгә хуш килә, дип мактый.

Шунысын да әйтәсем килә: мәчеттә каршы алу да бик мөһим.

> Кеше тәүге тапкыр Аллаһ йортына атлап кергәндә куркырга, шикләнергә дә мөмкин бит. Шуңа да аны ачык йөз күрсәтеп каршы алу, юнәлеш бирү мөһим.

Начар мөнәсәбәт кешенең бу урынга икенче тапкыр килүенә киртә булырга мөмкин. Мәсәлән, безгә экскурсия белән килеп керәләр, без: «Ачылганнан бирле көтәбез сезне!» – дип каршы алабыз. Аларга да рәхәт. Рәхмәт әйтеп чыгып китәләр.

Кеше мәчеткә килде, уңайлыкларны күрде, яхшы сүз ишетте, әйбәт мөнәсәбәт тойды, күзе белән матурлыкка сокланды. Тагын бер нәрсә кала: ул борыны белән дә хуш ис тоярга тиеш. Кайбер вакытта теге яисә бу урынны ис буенча да хәтердә калдырабыз бит. «Рауза»ны да шулай итеп искә алуларын теләдек. Махсус белгечләр хуш исле ислемайлар алып урнаштырды. Кайберәүләр: «Мәчет исе тыштан ук килә», – ди. Әйткәнемчә, кешегә мәчеттә рәхәт булырга тиеш. Безнең максатыбыз да шул.

:: Ачылганыгызга бер айдан вакыт узды. Мәчеткә кеше сукмак салдымы инде?

– Мәчетнең намаз залы 250 урынга исәпләнгән. Хатын-кызлар өчен балконда 75 урын бар. Әни, хатын-кыз исемен йөрткән мәчеттә гүзәл затларыбызга да урын булырга тиеш, билгеле. Күп мәчетләрдә җомга намазларында аларга урын җитми бит. Актык җомга намазына 230 ир-ат, 39 хатын-кыз килде. Шунысын да әйтим: ачылыш көнендә үзебез дә көтмәгән санга ирештек: җомгага 138 кеше килде! Әлхәмдүлилләһ, биш вакыт намазга да йөриләр.

Бер ай гына эшлибез, әмма күрсәткечләребез шөкер итәрлек. Әйтик, мәчеткә ике меңләп кеше килеп китте инде. Һәркайсына тиешле игътибар бирергә тырышабыз.

Җомга намазларына башка милләт вәкилләре дә килә. Бездә күпчелекне татарлар тәшкил итә, әлхәмдүлилләһ!

:: Иман йортының урыны да уңышлы сайланган, шулай бит?

– Бу территориядә мәчетләр юк. Кешеләрнең мәчеткә ихтыяҗы бар иде.

:: Никах укыту, балага исем куштыру ниятләре белән бу мәчеткә килеп буламы соң?

– Мәчет бу эшләрне дә башкара. Никах уку өчен аерым бүлмәбез бар. «Рауза» мәчетендә инде берничә никах та укылды. Балаларга исем дә куштык. Халыкның дини ихтыяҗын канәгатьләндерү юнәлешендә эш башланды, шөкер.

:: Биредә ислам нигезләренә өйрәтү каралганмы?

– Коръән укырга өйрәтү, хатын-кызлар өчен башлангыч дини белем бирү курслары бар. Төркемнәр тупладык. Укытучыларыбыз бик белемле, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган белгечләр. Курслар түләүле. Әмма бу – мәчет акча эшли дигән сүз түгел. Укырга йөргән кешенең дисциплинасы өчен шулай кирәк. Шуңа күрә символик түләү керттек. Теләсә кайсы бушлай бирелә торган әйбернең кадере булмый бит ул.

:: Илнур хәзрәт, күзәтүләрегездән чыгып, яшь буын дингә тартыла, дип әйтергә мөмкинме?

– Мәчеткә биш вакытка намазга йөрүчеләрнең яртысыннан күбрәге – яшьләр. Әлхәмдүлилләһ, Татарстандагы, Казандагы дини вазгыять шөкер итәрлек. Безгә мәчетләр кирәк! Алар чыннан да җитми.

:: Мәчетләр гуманитар ярдәм җыюга да кушылды. Бу җәһәттән «Рауза» мәчете нәрсә эшләде?

– Әйе, мәчет ачылу вакытында акча җыелды һәм без аны республикадан мобилизацияләнүчеләргә тапшырырга булдык. 200 мең сум акча җыелган иде.

Әңгәмәдәш – Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ЯШЬЛЕГЕМ БАСМАЛАРЫ

Бер-ике көн элек кинәт күңел купты: Шушма елгасын күрәсе килә башлады. Коелган тал яфрагы исе, сихри тынлык. Бу вакытта суы да ничектер икенче төсле була: аннан да көз исе, рәхәт салкынлык, саф һава бөркелә иде. Күңелне кузгатырга шушы хатирәләр җитеп ашты.

Авыл башыннан ярты чакрымлап читтән аккан Шушма елгасы, безнең авылга җитәрәк, бормаланып, күршеләребезнең бакча башыннан ук диярлек уза. Менә шул үзебездән күп дигәндә 100 метрлап читтә генә агучы, бик күп хатирәләрне үзендә саклаучы Шушмага күптән төшкән юк икән инде. Каз-үрдәк асрамагач, хаҗәте чыкмый, керне дә күптән анда чайкамыйбыз, савыт-саба юарга да анда төшмибез. Шушма буенда үскән, язгы ташу киткәч, ярындагы ләме кипкәнне көчкә көтеп җиткереп, кара көзгә кадәр шунда мәш килгән (әле кыш буе бәкедә кер чайкый идек) кеше димәссең, кайсы елны бер мәртәбә дә төшеп җитеп булмый. Дөрес, елга аша салынган күпердән узганда күрәбез Шушманы, анда да күп вакыт машина тәрәзәсеннән генә карап китәбез.

Билгеле, хәзер инде ул без үскәндәге Шушма түгел. Суы да кимеде, чисталыгы да элеккеге кебек түгел. Ярларын тал-чытырманлык басып бетерде. Шуңа күрә үзең генә төшәргә шомландыра да. Бу юлы да иптәшкә кызымны дәштем.

Без үскәндә, Шушмада безнең турыда гына да биш урында басма иде: Ибәт абыйлар басмасы, Зәйни абыйлар, Йосып бабайлар, Шамил абыйлар, Әхтәм абыйлар басмасы… Басманы гадәттә шушы абыйлар сала һәм карап тота, шуңа аларның исеме бирелә. Бүген араларыннан Әхтәм абый гына исән. Ибәт абыйлар турында су тирән, Зәйни абыйлар һәм безнең турыда ташлы һәм агым шактый көчле, Шамил абыйлар турында асты комлы һәм тын иде… Басмалар адым саен булса да, кайчакта әле кер чайкарга чират та була иде. Хәзер инде басмаларның кирәге калмады, аларны салучы да юк дип белә идем.

Яр буена якынрак барсам, аптырап киттем: безнең турыдан бераз түбәнрәк теге ярга чаклы киң итеп басма салганнар!

– Теге якка чыгып, ташлыкны карап керәм әле, – дим кызыма. Агачлар яфрак койган, әрәмәлекләр сирәгәйгән (үләннәрен кырау суккан), барырга, күрергә була, дим. Ташлык сүзе инде минем балаларыма да берни аңлатмый. Безнең исә балачак шунда үтте.

Үзем дә сизмәстән хатирәләргә биреләдем. Без белгәндә әле кечкенә генә бер утраучык иде ул. Берничә урында гына куакланып тал үсә башлаган. Калган өлеше ямь-яшел чирәм, комлык. Бөтен югары очның бала-чагасы шунда уйнап мәш килә, ләмком кушып, төрле тәмлүшкәләр дә «пешерәбез», бер-беребезгә кунакка йөрешәбез, хәтта туйлар да үткәрә идек. Зуррак балалар исә чиләктер, табакәстрүлдер, бөтенесен комлап, мунчалалап ышкып агарта. «Балык тота күрмәгез», – дип кат-кат кисәтеп, юарга дип кенә бирсәләр дә, ипи куәсе дә эшкә җигелә (аны салып, берничә минуттан алсаң, анда инде мыж балык керә иде), чайкарга дип алып төшкән әни-әбиләрнең яулыклары да сөзгеч ролен үти… Яулыкларның санаулы заманы бит, әни-әбиләр ничек түзде икән безгә, дип уйланам хәзер…

Шушы матур хатирәләргә бирелеп, киң, уңайлы итеп салынган басмага кергән идем, теге ярга көчкә чыгып җиттем. Суы аз булса да, агымы шактый, башны әйләндерергә ярап тора. Элек йөгереп йөргән басмадан курка-курка чыгуыма бер аптырасам, теге ярга чыгып җиткәч, бөтенләй гаҗәпкә калдым: ташлык юкка чыккан. «Ташлык та беткән икән», – дим теге ярда калган кызыма. «Ничек беткән?» – дип аптырый ул да. Теге матур утраучыктагы кечкенә таллар дистә еллар эчендә котырып үскән, ел саен язгы ташуда бөтен ләмне, пычракны үзләрендә бөяп калдыра-калдыра, теге яктагы шактый текә, биек яр белән тигезләшкән, аңа кушылган икән…

Моңсу булып китте. Юкса инде ташлыкның елдан-ел биегәя, чытырманлыкка әйләнә баруын күреп йөргән идек бит. Тик ике арадагы дистәләп метр киңлектәге, шундый ук биеклектәге бушлыкны тутырып, Шушма ярына тоташыр дип һич уйламый идем. Безнең балачак эзләре, самими хатирәләр дә шул яр астында калган, димәк…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6797 данә
Гомуми тираж – 15337 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 371

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+